Р Е С П У Б Л И К А   Т А Т А Р С Т А Н
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**посёлка городского типа**
**КУЙБЫШЕВСКИЙ ЗАТОН**
***Камско-Устьинского***
**м у н и ц и п а л ь н о г о   р а й о н а**

Т А Т А Р С Т А Н   Р Е С П У Б Л И К А С Ы
***Кама Тамагы***
**м у н и ц и п а л ь   р а й о н ы**
**КУЙБЫШЕВ ЗАТОНЫ**
**шәһәр тибындагы поселогы**
**Б А Ш Л Ы Г Ы**

ул. Ульяновское шоссед.8
Куйбышевский Затон , 422826
тел. (8277)59 -2-27, факс: (8277) 59-2-08
ОКПО 78702111 ОГРН 1061672000928
ИНН/КПП 1622004563/162201001

Ульяновское шоссе урамы, 8,Куйбышев Затонны штп, 422826,
тел. (8277)59 -2-27, факс: (8277) 59-2-08
ОКПО 78702111 ОГРН 1061672000928
ИНН/КПП 1622004563/162201001

КАРАР

№8 “01 август 2018 ел.”

“Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Куйбышев Затон шәхәр тибындагы поселогы” муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2017 елның 20 апрелендәге “Стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыруга шартнамә төзү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында” 4 санлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

“Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтү оештыру турында” 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ санлы Федераль закон нигезендә “Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Куйбышев Затон шәхәр тибындагы поселогы” муниципаль берәмлеге Башкарма комитетын карар бирә:

1. “Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Куйбышев Затон шәхәр тибындагы поселогы” муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2017 елның 20 апрелендәге 4 санлы карары белән расланган Стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыруга шартнамә төзү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 5 бүлекнең 5.4 пунктына 8, 9 пунктчасыларын өстәргә:

“8) муниципаль хезмәт курсәтү нәтиҗәләре буенча документлар тапшыру срогын яки тәртибен бозу;

9) муниципаль хезмәт курсәтүен туктату, әгәр туктату сәбәпләре федераль законнар һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясе норматив-хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм норматив-хокукый актлары, муниципаль хокукый актлары белән каралмаган булса.”.

2. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендлар аша халыкка белдерергә:

- Ульяновск шоссе ур. 8
- Больничный переулок ур. 3
- Парковая ур.

шулай ук мәгълүмат-телекоммуникация «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы районы рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуын үз өстемә алам.

Җитәкче Г.Р. Григорьева